| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 22 апрель г.Казань № 273

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге «Зәңгәр күлләр» комплекслы юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2003 ел, 16 июнь, 324 нче карары белән расланган Төбәк әһәмиятендәге «Зәңгәр күлләр» комплекслы юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге «Зәңгәр күлләр» комплекслы юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2003 ел, 16 июнь, 324 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 ел, 20 февраль, 80 нче; 2011 ел, 14 апрель, 295 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 2 апрель, 259 нчы; 2015 ел, 15 апрель, 253 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1223 нче; 2019 ел, 17 октябрь, 930 нчы; 2019 ел, 6 декабрь, 1119 нчы; 2019 ел, 30 декабрь, 1266 нчы; 2021 ел, 20 декабрь, 1255 нче; 2022 ел, 11 февраль, 111 нче; 2022 ел, 22 февраль, 152 нче; 2022 ел, 10 октябрь, 1090 нчы; 2023 ел, 30 ноябрь, 1536 нчы; 2024 ел, 18 март, 155 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төбәк әһәмиятендәге «Зәңгәр күлләр» комплекслы юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Тыюлык территориясендә тыюлыкның табигать комплексларына тискәре (зарарлы) йогынты ясый торган теләсә нинди эшчәнлек тыела, шул исәптән:

бу Нигезләмәнең 4.2 пунктындагы икенче абзацында каралган очраклардан тыш, биналар, төзелмәләр, корылмалар төзү;

бу Нигезләмәнең 4.2 пунктындагы өченче абзацында каралган очраклардан тыш, капиталь төзелеш объектларын, индивидуаль торак төзелеше объектларын төзү, шулай ук бакчачылыкны һәм яшелчәчелекне алып бару өчен җир кишәрлекләре бирү;

транспорт чараларын һәм авыл хуҗалыгы техникасын юу;

агызыла торган суларны, шул исәптән дренаж суларын агызу;

әгәр тыюблыкның табигать комплексларына зыян китерсәләр, гидрологик режимны үзгәртү, су ресурсларын эксплуатацияләү;

тыюлык эшчәнлегенә бәйле булмаган гидромелиорация һәм ирригация эшләрен башкару;

бу Нигезләмәнең 4.2 пунктындагы тугызынчы абзацында каралган очраклардан тыш, Кече Зәңгәр, Зур Зәңгәр күлләрендә, Агым сулы күлдә акваланг яки махсус җайланмалар белән күл төбенә төшү;

Комитетның мәгълүмат бирә торган билгеләрендә күрсәтелгән, су коену өчен махсус билгеләнгән урыннарда, тыюлыкта булу өчен рөхсәт ителгән вакытта су керүдән тыш, Кече Зәңгәр, Зур Зәңгәр күлләрендә, Агым сулы күлдә су коену;

бу Нигезләмәнең 4.2 пунктындагы унберенче абзацында каралган очраклардан тыш, эшмәкәрлек;

файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару, файдалы казылмалар ятмаларын эзләүне һәм бәяләүне үз эченә алган геологик өйрәнү, шулай ук җир асты байлыклары кишәрлекләренең файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен яраклылыгын геологик өйрәнү һәм бәяләү;

агачларны, куакларны кисү һәм (яки) үсемлек капламын бозу (урманнарның янгынга каршы корылышы буенча чаралар, урманнарны саклау, яклау һәм яңадан үстерү чараларын үткәрүдән, шулай ук табигать комплексларын һәм тыюлык объектларын саклап калу һәм яңадан торгызу максатларында әлеге эшчәнлек гамәлгә ашырыла торган очраклардан тыш);

барлык төрләрдәге калдыкларны урнаштыру, туфракларны, грунтларны, җир өсте һәм җир асты суларын пычрату;

материалларны, грунтларны, карны оеп кую;

учаклар кабызу, корыган яфракларны һәм үләннәрне яндыру;

туфрак катламын бозу, җир эшләрен башкару (урманнарның янгынга каршы корылышы чараларын башкарудан, фәнни тикшеренүләр үткәрү очракларыннан тыш, шулай ук бу Нигезләмәнең 4.2 пунктындагы икенче абзацы нигезендә төзергә рөхсәт ителә торган объектлар төзүгә бәйле очраклардан тыш);

яшәү тирәлегеннән алып, хайваннар дөньясы объектларыннан файдалану, шулай ук хайваннар дөньясы объектларына зыян китерү (хайваннар дөньясы объектларын фәнни максатларда, һәвәскәр һәм спорт аучылыгы максатларында

файдаланудан, аларның санын җайга салу, шулай ук сирәк һәм юкка чыгу куркынычы яный торган хайваннар дөньясы объектларының популяцияләрен торгызу буенча чараларны гамәлгә ашырудан тыш);

хайваннарның ояларын, өннәрен һәм башка яшәү урыннарын бетерү, шулай ук кыргый хайваннарны борчуга китерә торган башка гамәлләр кылу;

киртәләргә, аншлагларга, шлагбаумнарга, стендларга, чик баганаларына, күрсәткечләргә һәм башка мәгълүмат билгеләренә, эшләнгән экологик сукмакларга, төзелмәләргә һәм корылмаларга зыян салу, агачларга язулар һәм билгеләр төшерү;

түбәндәге механик транспорт чаралары, махсуслаштырылган техникасы, йөзү чараларыннан тыш, механик транспорт чаралары йөрү һәм туктап тору, барлык йөзү чаралары (шул исәптән аз үлчәмле суднолар) узу һәм туктап тору:

махсус саклана торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органнарның;

тыюлык чикләрендә вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган башка дәүләт һәм муниципаль органнарның;

линия объектларына хезмәт күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру, аварияләрне, табигый бәла-казаларны һәм гадәттән тыш характердагы башка хәлләрне бетерү чараларын үткәрү өчен файдаланыла торган;

«Татарстан көзгеләре» туристлык-рекреация кластеры кысаларында чараларны гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган;

шулай ук түбәндәге механик транспорт чараларыннан тыш:

аучылык хуҗалыгы килешүләре нигезендә хайваннар дөньясыннан файдалануны гамәлгә ашыручы юридик затларның, индивидуаль эшмәкәрләрнең;

шартнамәләр нигезендә тыюлык территориясендә хезмәт күрсәтүче юридик затларның, индивидуаль эшмәкәрләрнең;

фәнни һәм экологик чараларны гамәлгә ашыручы юридик затларның, индивидуаль эшмәкәрләрнең, физик затларның, шул исәптән Кече Зәңгәр, Зур Зәңгәр күлләре, Агым сулы күл төбенә төшү, акваланг яки махсус корылмалар белән күл төбенә төшү юлы белән;

түбәндәге чорларда тыюлык территориясендә физик затлар булу:

майдан алып августка кадәр – 22 сәгать 00 минуттан 5 сәгать 00 минутка кадәр;

сентябрьдән алып апрельгә кадәр – 18 сәгать 00 минуттан 8 сәгать 00 минутка кадәр, тыюлык территориясендә тыюлык чикләрендә вәкаләтләрен башкаручы дәүләт һәм муниципаль органнарның вазыйфаи затлары, шулай ук махсус саклана торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы затларның булуыннан; линия объектларына хезмәт күрсәтү чараларыннан, аварияләрне, табигый бәла-казаларны һәм гадәттән тыш характердагы башка хәлләрне бетерү чараларыннан; «Татарстан көзгеләре» туристлык-рекреация кластеры кысаларында чаралардан; хайваннар дөньясыннан аучылык хуҗалыгы килешүләре нигезендә файдаланудан; шартнамәләр нигезендә тыюлык территориясендә хезмәт күрсәтүдән; фәнни һәм экологик чаралардан тыш;

тыюлыктагы табигать комплексының экологик тигезлеген боза торган, тыюлык территориясенең экологик кыйммәтен киметә яки хайваннар һәм үсемлекләр дөньясының сакланыла торган объектларына һәм аларның яшәү тирәлегенә зыян китерә торган башка эшчәнлек төрләре.»;

4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Тыюлык территориясендә, Комитет белән килештереп, түбәндәгеләр рөхсәт ителә:

тыюлык булдыру максатларына ирешүгә һәм аның төп бурычларын хәл итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән объектлар төзү һәм реконструкцияләү; яңа инженерлык һәм техник коммуникацияләр төзү, элек төзелгәннәрне реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм ремонтлау (тыюлыкның чикләреннән чыгып аларны урнаштыру вариантлары булмаган очракта); элегрәк төзелгән капиталь төзелеш объектларын, шул исәптән линия объектларын реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм ремонтлау;

бу пунктның икенче абзацы нигезендә төзергә рөхсәт ителә торган объектларны төзү өчен җир кишәрлекләре бирү;

җир кишәрлекләрен һәм су объектларын экологик реабилитацияләү, җир кишәрлекләрен рекультивацияләү;

үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектларын, шул исәптән Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән төрләрен, шулай ук аларның яшәү тирәлеге мохитен саклау чараларын гамәлгә ашыру;

үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектларының, шул исәптән Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән төрләрнең яшәү тирәлеге шартларын яхшыртуга ярдәм итә торган профилактика чараларын үткәрү;

су объектларының яр буе яклау полосалары чикләрендә һәм хайваннар дөньясы объектларының яшәү тирәлеге буларак аеруча кыйммәтле булган кишәрлекләрдә камыш әзерләү һәм чабу;

урманнарны саклау, яклау һәм яңадан үстерү чараларын үткәрү, урманнарны яклау буенча профилактик чаралар, санитария-савыктыру чаралары, шул исәптән һәлак булган һәм зыян күргән урман утыртмаларын кисү (1 апрельдән 31 июльгә кадәр ояда утыру һәм балалар чыгару чорында агачлар кисүдән тыш);

биотөрлелекне, табигать комплексларын һәм тыюлыклар объектларын өйрәнүгә һәм торгызуга, мәдәни мирас объектларын өйрәнүгә һәм саклауга юнәлдерелгән фәнни тикшеренүләр уздыру, шулай ук экологик чаралар, шул исәптән Кече Зәңгәр, Зур Зәңгәр күлләре, Агым сулы күл төбенә төшү, акваланг яки махсус корылмалар белән күл төбенә төшү юлы белән үткәрү;

экологик туризмны гамәлгә ашыру;

«Татарстан көзгеләре» туристлык-рекреация кластерын гамәлгә ашыру максатларында эшмәкәрлек;

«Татарстан көзгеләре» туристлык-рекреация кластерын гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән объектлар, биналар һәм корылмалар төзү, аларны реконструкцияләү

һәм капиталь ремонтлау (су коену өчен махсус бүлеп алынган һәм билгеләнгән су керү урыннарын төзекләндерүне кертеп);

печән чабу, мал-туар көтү;

умарта ояларын һәм умарталыклар урнаштыру.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин